ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 апреля 2022г. № 2129

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондындагы торак урыннары бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатында, 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 31 337 сум 14 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 363 536 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 2 727 072 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 4 090 608 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 5 454 144 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 6 817 680 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 8 181 216 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 9 544 752 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 10 908 288 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов